КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 4 июль г.Казань № 543

Агачлар һәм куаклар үстерүгә, шулай ук аларны юкка чыгарылган яки зарарланган яшькә кадәр карауга турыдан-туры бәйле булган чыгымнар нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы территориясендә үсә торган, урман үсентеләренә кертелмәгән агачларга һәм куакларга китерелгән зыян күләмен билгеләү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман законнарын бозу аркасында урманнарга китерелгән зыян күләмен исәпләү турында» 2007 ел, 8 май, 273 нче карар белән расланган Урман законнарын бозу аркасында урманнарга, шул исәптән урман үсентеләренә яки урман үсентеләренә кертелмәгән агачларга, куакларга һәм яфраннарга китерелгән зыян күләмен исәпләү методикасының 13 нче пунктына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән агачлар һәм куаклар үстерүгә, шулай ук аларны юкка чыгарылган яки зарарланган яшькә кадәр карауга турыдан-туры бәйле булган чыгымнар нормативларын расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына бу карарның 1 нче пунктында билгеләнгән чыгымнар нормативларын куллануны тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 4 июль, 543 нче карары белән расланды

**Агачлар һәм куаклар үстерүгә, шулай ук аларны юкка чыгарылган яки зарарланган яшькә кадәр карауга турыдан-туры бәйле булган чыгымнар нормативлары**

(сум)

| Төре | Кәүсә диаметры 12 см һәм аннан да артыграк булган 1 куб метр агач өчен чыгымнар нормативы | Кәүсә диаметры 12 см га кадәр җитмәгән 1 куб метр агач өчен чыгымнар нормативы | Ылыслы һәм яфраклы төрләрдәге 1 куак өчен чыгымнар нормативы |
|---|---|---|---|
| Ылыслы төрләрдәге агачлар | 1 992,82 | 1 812,49 | - |
| Агач әзерләү рөхсәт ителми торган ылыслы төрләрдәге агачлар | 5 978,45 | 5 437,46 | - |
| Йомшак яфраклы төрләрдәге агачлар | 1 247,60 | 1 134,71 | - |
| Агач әзерләү рөхсәт ителми торган йомшак яфраклы төрләрдәге агачлар | 3 742,81 | 3 404,13 | - |
| Каты яфраклы төрләрдәге агачлар | 3 053,71 | 2 932,68 | - |
| Агач әзерләү рөхсәт ителми торган каты яфраклы төрләрдәге агачлар | 9 161,14 | 8 798,04 | - |
| Агач әзерләү рөхсәт ителми торган куаклар | - | - | 2 929,75 |
| Башка куаклар | - | - | 976,58 |